ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е          К А Р А Р

«19» ноябрь 2019 ел          №1985

2020 елга Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең сәнгати-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан республикасында балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 нче карары һәм Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы "Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга расларга:

Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 0,5 күләмендә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты.

2.Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна

учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына В. В. Друкка йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Г.Х. Зарипова
5-10-39

Расланды

“Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән

19 ноябрь 2019 ел №1985

# 2020 елга Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (жер укучыга елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | иртәпрофессиональ ориентация |
| Музыкаль сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | Авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | Шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | Авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | Авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | Авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | Авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | Шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | Авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |